Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районының
Югары Шепкә авыл җирлеге Советы

**КАРАРЫ**

№ 135 24 март 2025 ел.

**Бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында Зәй муниципаль районының Югары Шепкә авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен Татарстан Республикасы «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында»**

2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Шепкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Шепкә авыл җирлеге Советы

**Карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, аның график сурәтен дә кертеп, 2025 елның 29 мартыннан да соңга калмыйча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең Югары Шепкә, Имәнлебаш, Иске Пәлчикәү, Бәләкәй Пәлчикәү авыллары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, түбәндәге адреслар буенча:
Югары Шепкә ав., Үзәк ур., 50 й.;
Имәнлебаш авылы, Үзәк ур., 63 й. ;
Иске Пәлчикәү ав., Үзәк ур., 19 й.;
Бәләкәй Пәлчикәү ав ., Үзәк ур., 3 й.

3. Карар ул басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Совет Рәисе Л.М. Камалиева

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль
районының Югары Шепкә авыл җирлеге
Советының 2025 елның 24 мартындагы
135 номерлы карарына Кушымта

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Советы депутатларын сайлаулар уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасы**

**№1 нче бермандатлы топ сайлау округы**

Сайлаучылар саны-92

Округка Татарстан Республикасы Югары Шипкә муниципаль районы Югары Шипкә авыл җирлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Югары Шипкә авылы, Үзәк урам, 1-65 номерлы (җөп як), 2-56 номерлы (җөп як), 1-11/2 номерлы Яшьләр урамы (җөп як)

**№2 нче бермандатлы елга сайлау округы**

Сайлаучылар саны-106

Округка Татарстан Республикасы Югары Шипкә муниципаль районы Югары Шипкә авыл җирлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Югары Шипкә авылы, М. Вахитов урамы, 1-69 номерлы йортлар, 1-29 номерлы Елга урамы, 58-72 номерлы Үзәк урам (җөп як), 69-79 номерлы (так як)

**№3 нче бермандатлы Үзәк сайлау округы**

Сайлаучылар саны - 105

Округка Татарстан Республикасы Югары Шипкә муниципаль районы Югары Шипкә авыл җирлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Югары Шипкә авылы, Г. Гафиятуллин урамы, 1-13 номерлы йортлар, К. Маркс урамы, 1-32 номерлы йортлар, Үзәк урам по 69 -107(җөп як) по 78-90 (җөп як), м. Вахитов урамы по 75-95

**№4 нче бермандатлы Мәктәп сайлау округы**

Сайлаучылар саны - 112

Округка Татарстан Республикасы Югары Шипкә муниципаль районы Югары Шипкә авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Югары

Шипкә авылы, Яшьләр урамы, йортлар №№ 13, 15,17, 19, 23, Мәктәп урамы, М. Җәлил урамы, Х. Такташ урамы, Г. Тукай урамы, Үзәк урам, 67 нче йорт

**№5 нче завод бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны-113

Округка Татарстан Республикасы Югары Шипкә муниципаль районы Югары Шипкә авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Югары Шипкә авылы, Яшьләр урамы, 4-52 нче йортлар (җөп як)), № 25, № 27, № 29, № 31, 47, Завод урамы, Имәнлебаш авылы, Үзәк урам, по 34 № 128 № 134 йортлар

**№6 нчы бермандатлы клуб сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 115

Округка Татарстан Республикасы Югары Шипкә муниципаль районы Югары Шипкә авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Имәнлебаш авылы, Үзәк урам, 1-115 номерлы йортлар (так як), 38-122 номерлы йортлар (җөп як)

**№7 нче Ленин бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны-96

Округка Татарстан Республикасы Югары Шепкә муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Имәнлебаш авылы, Ленин урамы, 1-34 нче йортлар, Иске Пәлчикәү авылы, Үзәк урам, Елга урамы, Бәләкәй Пәлчикәү авылы, Үзәк урам, 1 нче, 26 нчы йортлар

## Округлар схемасының график сурәте

| Округ № | Төс | Округ исеме |
|---|---|---|
| 1 | | Төп |
| 2 | | Елга |
| 3 | | Үзәк |
| 4 | | Мактап |
| 5 | | Завод |
| 6 | | Клуб |
| 7 | | Ленин |

